ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 324 от «18» 08 2023 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
туберкулезга каршы көрәш буенча
ведомствоара комиссия төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә туберкулез таралуны кисәтү турында» 2001 елның 18 июнендәге 77-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Мамадыш районы халкы арасында туберкулез белән авыруны профилактикалау, иртә ачыклау, киметү буенча кичектергесез чаралар күрү максатында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында туберкулезга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составы (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында туберкулезга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Ш.Фатыховка йөкләргә.

Җитәкче О.Н. Павлов

0000011915

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
«18» 08 2023 ел № 324
Карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында туберкулезга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Фатыхов Н.Ш. | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - комиссия рәисе; |
| Гарипов Р.З. | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы - комиссия рәисе урынбасары; |
| Левина Г.Ф. | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ врач-фтизиатры, комиссия секретаре; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гарифуллин А.А. | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Яшьләр эшләре буенча спорт бүлеге җитәкчесе. |
| Габдрахманов И.Н. | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе. |
| Горбунов А.П. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе; |
| Исхаков И.И. | Эчке эшләр министрылыгының Мамадыш районы буенча булеге башлыгы вазыфаларын башкаручы; |
| Мәснәвиева М.Х. | Саба, Мамадыш, Кукмара районнарында кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлеге белгеч-эксперты. |
| Ханова С.Н. | «Татмедиа» АҖ филиалы «Мамадыш- информ» баш мөхәрире-җитәкчесе |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
«18» 08 2023 ел, № 324
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында туберкулезга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмә.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Районның Башкарма комитеты каршындагы туберкулез белән көрәш буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) беркетелгән территориядә җирле Сәламәтлек саклау учреждениесе, кызыксынган хезмәтләр һәм туберкулез белән көрәш буенча ведомстволар эшен координацияләүче орган булып тора.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

туберкулезга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия:

2.1. Комиссия карарларын үтәү өчен кабул ителгән чаралар турында комиссиягә билгеләнгән срокларда хәбәр итәргә тиешле учреждениеләр, предприятиеләр, вазифаи затлар өчен мәҗбүри булган туберкулез белән көрәш мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә.

2.2. Туберкулез белән көрәш буенча дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә.

2.3. Туберкулез таралуны кисәтү буенча чараларны турыдан-туры да, тиешле дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалар аша да эшли һәм гамәлгә ашыра.

2.4. Эчке эшләр органнары, Санэпиднадзор үзәкләре һәм туберкулез белән көрәш буенча Сәламәтлек саклау учреждениеләре эшен контрольдә тота.

2.5. Комиссия утырышларында предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләренең туберкулез таралуга каршы көрәш һәм аны иртә ачыклауны тәэмин итү чаралары турында хисапларын тыңлый.

2.6. Туберкулезга халыкны профилактик тикшерүне оештыруны контрольдә тота.

2.7. Туберкулезга каршы хезмәтнең матди-техник базасын ныгыту мәсьәләләрен хәл итүне, аның кадрлар белән комплектлануын контрольдә тота.

2.8. Беркетелгән территориядә авыл хуҗалыгы хайваннары һәм кошлары туберкулезы белән көрәш торышын, шулай ук терлекчелек һәм кошчылык хезмәткәрләре арасында профилактик чаралар үткәрүне контрольдә тота.

2.9. Туберкулезны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрмәгән җитәкчеләргә таләпчәнлекне көчәйтү турында тиешле органнарга һәм ведомстволарга тәкъдимнәр белән керә.

2.10. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- Туберкулезны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрмәгән җитәкчеләргә таләпчәнлекне көчәйтү турында тиешле органнарга һәм ведомстволарга тәкъдимнәр белән керә.;

- комиссия эше өчен кирәкле материаллар һәм мәгълүматны җитәкчеләрдән һәм учреждениеләрдән, аларның ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына карамастан, сорарга.

2.11. Комиссия бурычлы:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында халыкның туберкулез белән авыру күрсәткечләренә динамик анализ ясау.

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында халык арасында туберкулезга профилактик тикшерүләр оештыруны һәм үткәрүне анализлау.

## 3. Комиссия эшен оештыру

3.1. Комиссия рәисе комиссияне даими (кварталга 1 тапкыр) чакыруны тәэмин итә, чираттагы утырышта каралырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели, Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

3.2. Комиссия утырышы аның составының яртысыннан ким булмаган өлеше булганда хокукды.

3.3. Комиссия карары комиссия әгъзаларының күпчелек тавышлары белән кабул ителә.

3.4. Комиссия утырышы карала торган мәсьәләләрнең характеры һәм эчтәлеге күрсәтелгән протокол белән рәсмиләштерелә. Протоколга рәислек итүче һәм секретарь кул куя.

3.5. Комиссиянең шәхси составы һәм аның Рәисе Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана. Комиссия әгъзалары комиссия эшендә шәхси катнашалар.

3.6. Комиссиянең чираттан тыш утырышы комиссия әгъзасы тарафыннан Комиссия рәисенә нигезле тәкъдим белән инициативаланырга мөмкин. Комиссия утырышларына прокуратура, суд, эшкуарлык структуралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, авыл җирлекләре башлыклары, медицина белгечләре,

предприятие җитәкчеләре, комиссиядә карала торган мәсьәләләр кысаларында кызыксынган башка затлар чакырылырга мөмкин.

3.7. Чираттан тыш утырыш үткәрү турында карарны комиссия рәисе кабул итә.

3.8. Комиссия утырышлары ачык утырышлар һәм ябык утырышлар формасында да үткәрелергә мөмкин. Үткәрү формасы турында карар комиссия әгъзаларының гомуми составының күпчелек тавышлары белән кабул ителә.